Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Ислэй авыл җирлеге Советы

29 август 2023 ел № 33/2

КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислэй авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 августындагы “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәне раслау турында”гы 11/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Авыл җирлеге Советның 2021 елның 16 августындагы 11/2 номерлы карарына 2023 елның 31 июлендәге 02-08-02-2023 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислэй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислэй авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 августындагы 11/2 номерлы Чистай муниципаль районы “Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 15 пунктта:

беренче абзацта «яисә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны төшереп калдырырга;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 16-17 пунктлар өстәргә:

«16. Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырган очракта, йә ялган булган белешмәләрне тапшыру муниципаль хезмәткәрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

17. Әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгәнчә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Исләй авыл җирлеге
башлыгы В.П.Чернышев